РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11 » 10 2023 г. №1601

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 30 октябрендәге 756 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Сыйфат стандартына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 29.12.2012 ел, N 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 30 октябрендәге 756 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп белем бирү программалары буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Сыйфат стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Сыйфат стандартының 7.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Оешма укырга керүчене һәм (яисә) аның ата-анасын (законлы вәкилләрен) үз уставы, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе, гамәлгә ашырыла торган белем бирү программалары буенча белем бирү

эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе бирү датасы һәм теркәү номеры турындагы мәгълүматлар, белем бирү программалары һәм белем бирү эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны, укучыларның хокукларын һәм бурычларын регламентташтыручы башка документлар белән таныштырырга тиеш.».

1.2. Сыйфат стандартының 9.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.4. Оешмалар «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ Федераль законның 29 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматның һәм документларның ачыклыгын һәм теләк белдергән һәркем карый алырлык булуын тәэмин итәләр".

1.3. Сыйфат стандартының 7 нче абзацы 9.4 пункты 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- федераль дәүләт белем бирү стандартлары, федераль дәүләт таләпләре, мәгариф стандартлары һәм мөстәкыйль билгеләнгән таләпләр турында (алар булган очракта);»

1.4. Сыйфат стандартының 8 нче бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина